**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«15» май 2020 с. Тюлячи № 226

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының «Хәрби хезмәт нигезләре буенча әзерлек уза торган укучылар белән укыту-кыр җыеннары үткәрү турында» 2020 елның 7 маендагы 209 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

МКУ «Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты мәгариф бүлеге»нең 2020 елның 14 маендагы № 146 номерлы хатын карап, «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» Федераль закон таләпләрен, «Россия Федерациясе гражданнарын хәрби хезмәткә өйрәтүне оештыру инструкциясен раслау турында» 2010 елның 24 февралендәге 96/134 номерлы боерыгын һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1999 елның 31 декабрендәге 1441 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясе гражданнарын хәрби хезмәткә әзерләү турында Нигезләмәне үтәү йөзеннән,«Татарстан Республикасында яңа коронавирус инфекциясе таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 елның 19 мартындагы 208 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 26 февралендәге 417-р номерлы күрсәтмәсе нигезендә, Теләче мниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының «Хәрби хезмәт нигезләре буенча әзерлек уза торган укучылар белән укыту-кыр җыеннары үткәрү турында» 2020 елның 7 маендагы 209 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 пунктны түбәндәге эчтәлекле сүзләр белән тулыландырырга: «, дистанцион формада. Зачетларны дистанцион форматта кабул итәргә.»;

2) 2 пунктта «, кече калибрлы винтовкадан ату күнегүләрен үтәүне оештыруны һәм ату уздырганда куркынычсызлык чараларын тәэмин итүне оештыруны Татарстан Республикасы ДОСААФ Теләче җирле оешмасы советы рәисе Р.Р. Нуретдиновка йөкләргә» сүзләрен төшереп калдырырга;

3) пунктны түбәндәге тәртиптә бәян итәргә:

«3. ТР Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» (Карпова Н.В.):

- уку җыеннарына җәлеп ителә торган укучыларның составын билгеләргә, район мәгариф учреждениеләренең 10 сыйныф ир-егет гражданнарының тулысынча булуын тәэмин итәргә.»;

4) 4-6 пунктларны төшереп калдырырга;

5) 7 пунктны 4 пункт дип санарга.

2. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Җитәкче Н.Н. Хаҗипов